**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № ______

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2021-2022 еллардагы ягулык сезонын тәмамлау һәм 2022-2023 елларның көзге-кышкы чорында җылыту сезонына әзерләнү турында**

Тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы +8 градустан артып китү сәбәпле һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында» 2006 елның 23 маендагы 307 номерлы карары нигезендә, торак-коммуналь хуҗалык, ягулык-энергетика комплексы предприятиеләрен һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны 2022-2023 нче еллар ягулык сезонына үз вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районының социаль объектларын, торак фондын һәм башка кулланучыларын җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләргә һәм оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1.1. 2021-2022 еллардагы җылыту сезонын, 2022 елның 04 нче маенда тәмамларга.

1.2. Объектларны көзге-кышкы чорда эшләүгә әзерләү чаралары нигезендә котельныйларда, үзәк җылылык пунктларында, тышкы челтәрләрдә һәм эчке инженерлык системаларында ремонт һәм профилактик эшләргә керешергә.

2. Объектларны 2022-2023 елларда көзге-кышкы чорда эшләүгә әзерләүне 2022 елның 15 сентябренә тәмамларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов